РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.02.2019 № 11-п

Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының
«Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда
тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын
раслау турында " 2014 елның 20 нче гыйнварендә
3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Район прокуратурасының 18.02.2019 №02-08-02-42-2019 протесты һәм 2018 елның 27 декабрендәге 558-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп төзүне һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" гы Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының «муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 21 нче апрелендә 21 а номерлы карары белән расланган “Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламенты”на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.1 пунктның 6 пунктчасында “әлеге йортта гомуми милекне агымдагы һәм капиталь ремонтлау тәртибе” сүзләреннән соң “күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп төзүне гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адреслары буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гараевка йөкләргә.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев